**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 175** **18.06.2025 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Дүрт Мунча авыл җирлеге Советының**
**бишенче чакырылыш депутатларын**
**сайлауларны билгеләү турында**

Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктлары нигезендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында», 6 статьяның 2 өлеше, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Дүрт Мунча авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 һәм 32 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Советы

**карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт Мунча авыл җирлеге Советының бишенче чакырылыш депутатларын сайлауларны 2025 елның 14 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны, ул кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, «Яңа Зәй», «Зәй офыклары» газеталарында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керүен билгеләргә.

**Дүрт Мунча авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **Р.Т.Ситдиков**